**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 2 апрель № 211

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җирләрдән җир кишәрлеген башка категориягә күчерү турындагы үтенечнамә формасын һәм аңа теркәлә торган документлар составын раслау хакында» 2006 ел, 25 октябрь, 523 нче карары белән расланган авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җирләрдән җир кишәрлеген башка категориягә күчерү турындагы үтенечнамә формасын һәм аңа теркәлә торган документлар составына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җирләрдән җир кишәрлеген башка категориягә күчерү турындагы үтенечнамә формасын һәм аңа теркәлә торган документлар составын раслау хакында» 2006 ел, 25 октябрь, 523 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 28 март, 112 нче; 2008 ел, 14 апрель, 232 нче; 2009 ел, 1 июнь, 353 нче; 2010 ел, 20 апрель, 279 нчы; 2010 ел, 19 август, 667 нче; 2011 ел, 29 август, 725 нче; 2012 ел, 13 февраль, 110 нчы; 2012 ел, 25 май, 418 нче; 2013 ел, 26 сентябрь, 684 нче һәм 2014 ел, 6 август, 572 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җирләрдән җир кишәрлеген башка категориягә күчерү турындагы үтенечнамәгә теркәлә торган документлар составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Җир кишәрлегенә хокук иясенең бер категориядәге җирләр составындагы җир кишәрлеген икенче категориягә күчерүгә (алга таба – җир кишәрлекләрен күчерү) ризалыгы, моңа җир кишәрлегенә хокук иясе мондый җир кишәрлегенә карата сервитут билгеләү турында килешү төзегән зат булган очрак керми.

Дәүләт милкендәге һәм муниципаль милектәге җир кишәрлекләрен күчерүгә әлеге җир кишәрлекләре белән эш итүгә вәкаләтле җирле үзидарә органы ризалыгы карар рәвешендә кертелә.»;

8 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Җир кишәрлеген ясарга кирәк булса һәм чикләрендә мондый җир кишәрлеген ясарга кирәк булачак территорияне межалау проекты булмаса, кәгазь чыганакта әзерләнгән җир кишәрлеге урнашу схемасын теркәп, вәкаләтле җирле үзидарә органының җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү турындагы карары (җир кишәрлеген ясарга йә аның чикләрен тәгаенләргә кирәк булганда җир кишәрлеге дәүләт милкендәге яки муниципаль милектәге җирләрдән Россия Федерациясе Җир кодексының 39.15 статьясындагы 1 нче пунктның 6 нчы пунктчасында күрсәтелгән нигезләр буенча бирелгән очракта).»;

түбәндәге эчтәлекле 8.1 нче һәм 8.2 нче пунктлар өстәргә:

«8.1. Җир кишәрлеген арендалау турында шартнамә күчермәсе (ул төзелгән булса һәм Күчемсез мөлкәткә хокуклар һәм аның белән алыш-бирешләр бердәм дәүләт реестрында аңа булган хокукларның аренда рәвешендәге чикләүләре (йөкләмәләре) турында мәгълүматлар булмаса).

8.2. 2018 елның 1 мартына кадәр – җир кишәрлеген сайлап алу актын теркәп, объектны урнаштыру урынын алдан килештерү турында вәкаләтле җирле үзидарә органы карары (әгәр җир кишәрлеге дәүләт милкендәге яки муниципаль милектәге җирләрдән бирелсә, объектны урнаштыру урынын алдан килештереп, 2015 елның 1 мартына кадәр, әмма Россия Федерациясе Җир кодексының 31 һәм 32 статьялары нигезендә («Россия Федерациясе Җир кодексына һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2014 ел, 23 июнь, ФЗ-171 нче Федераль закон үз көченә кергән көнгә кадәр гамәлдә булган редакциясендә) җир кишәрлеген бирүгә өч елдан да алданрак булмаган вакытта кабул ителгән.»;

10 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Җир кишәрлеге файдалы казылмалар чыгаруга бәйле рәвештә күчерелгән очракта – үтенечнамәгә түбәндәгеләрнең нотариатта йә җитәкче яки моңа ул вәкаләт биргән вазыйфаи зат имзасы һәм җир асты байлыкларыннан файдаланучы булган оешма мөһере белән таныкланган күчермәләре теркәлә:

җир асты байлыкларыннан файдалану хокукына лицензиянең;

лицензиягә (ул булганда) өстәмә килешүнең (өстәмәнең);

план-карта материалына, бүлеп бирелә торган файдалы казылма кишәрлеге чикләрен күрсәтеп (таяну, параметр, структура, эзләнү, бәяләү һәм разведка скважиналарын урнаштырудан тыш), файдалы казылма кишәрлеген бүлеп бирү актының.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков